Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт шәһәр Советы
КАРАРЫ

13 июль 2022 ел № 73

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2016 елның 10 августындагы 42 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәренең муниципаль хезмәткәрләрен һәм муниципаль хезмәткәр вазифаларын биләүче затлар өчен премияләр бирү һәм башка өстәмә түләүләр турында нигезләмә хакында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәренең муниципаль вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәткәрләрен биләүче затларның хезмәте өчен түләү системасын камилләштерү максатларында,

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Советының 2016 елның 10 августындагы 42 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәренең муниципаль хезмәткәрләрен һәм муниципаль хезмәткәр вазифаларын биләүче затлар өчен премияләр бирү һәм башка өстәмә түләүләр турында нигезләмә хакында»гы карарына» (Әлмәт шәһәр Советының 2016 елның 06 октябрендәге 48 номерлы, 2016 елның 28 декабрендәге 61 номерлы, 2018 елның 31 маендагы 121 номерлы, 2019 елның 28 августындагы 167 номерлы, 2021 елның 22 июлендәге 41 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) карарга 1 нче кушымтада:

1 бүлектә:

1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Әлеге карар белән билгеләнгән премияләрне һәм башка өстәмә түләүләрне финанслау чыгымнары, агымдагы финанс елына бюджет турында карар белән расланган керемнәрдән, фактта алынган акчаларны һәм агымдагы финанс елы башына район бюджеты счетындагы акчаларның калган өлешен, оптимальләштерү чараларын үткәрү, бюджет чыгымнарының аерым статьялары буенча бюджет ассигнованиеләрен кыскарту булганда, җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.»;

б) карарга 2 нче кушымтада:

1 пунктта:

- беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хезмәткәрнең катлаулы һәм киеренкелеге өчен айлык түләү вазыйфаи окладның 180 проценты күләмендә билгеләнә.»;

- икенче һәм өченче абзацларны үз көчләрен югалткан дип санарга;

- дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен түләү билгеләү турындагы карар эш бирүче тарафыннан кабул ителә.»;

2 пунктны үз көчен югалткан дип санарга.

2.Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2022 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Мусин Р.Ф.).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов